**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Зеленая Роща авыл җирлеге**
**Спиридоновка авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2020 елның 21 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Спиридоновка авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Зеленая Роща авыл җирлеге Спиридоновка авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге Спиридоновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче һәм икенче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 250 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Ленин урамы буенча юл өлешчә өелә;

- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт, Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы, Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32 нче йорт Спиридоновка авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зеленая Роща авыл җирлеге башлыгы А.А.Потапов